ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**от 16.12.2014** г. Казань **№ 405**

**Татарстан Республикасы территориясендә электр энергиясен (егәрлеген) кулланунын̧ социаль нормасын урнаштыру һәм куллану мәсьәләләре буенча мәгълүмәт алмашу регламентын раслау турында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең “Электр энергиясен (егәрлеген) кулланунын̧ социаль нормасын урнаштыру һәм куллану тәртибе турындагы һәм Россия Федерациясенең электр энергиясен (егәрлеген) кулланунын̧ социаль нормасын урнаштыру һәм куллану мәсьәләләре буенча кайбер актларына үзгәрешләр кертү турындагы” 22.07.2013 ел № 614 карарын үтәү йөзеннән боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы территориясендә электр энергиясен (егәрлеген) кулланунын̧ социаль нормасын билгеләү һәм куллану мәсьәләләре буенча мәгълүмәтне Татарстан Республикасынын̧ кызыксынучы башкарма хакимият органнары, Россия Федераль миграция службасынын̧ Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Федерациясе Пенсия фондынын̧ Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе, халыкны социаль яклау органнары, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, коммуналь хезмәтләрне башкаручылар, башка органнар һәм оешмалар арасында алмашу регламентын кушымтага ярашлы рәвештә расларга.

2. Шушы боерык аны рәсми игълан иткән көннән ун көн үткәч үз көченә керә.

3. Шушы боерыкнын̧ үтәлешенә контрольне үземә калдырам.

Рәис М.Р.Зарипов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
_____________ № _______ боерыгына
кушымта

Татарстан Республикасы территориясендә электр энергиясен (егәрлеген) куллануның социаль нормасын билгеләү һәм куллану мәсьәләләре буенча мәгълүмәтне Татарстан Республикасының кызыксынучы башкарма хакимият органнары, Россия Федераль миграция службасының Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе, халыкны социаль яклау органнары, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, коммуналь хезмәтләрне башкаручылар, башка органнар һәм оешмалар арасында алмашу

# РЕГЛАМЕНТЫ

## I. Гомуми положениеләр

1. Татарстан Республикасы территориясендә электр энергиясен (егәрлеген) куллануның социаль нормасын билгеләү һәм куллану мәсьәләләре буенча мәгълүмәтне Татарстан Республикасының кызыксынучы башкарма хакимият органнары, Россия Федераль миграция службасының Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе, халыкны социаль яклау органнары, ресурслар белән тәэмин итүче оешмалар, коммуналь хезмәтләрне башкаручылар, башка органнар һәм оешмалар арасында алмашу регламенты (арытаба – Регламент) Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 22.07.2013 ел № 614 карары белән расланган Электр энергиясен (егәрлеген) куллануның социаль нормасын билгеләү һәм куллану турындагы положениегә (арытаба – Положение) ярашлы рәвештә төзелгән һәм мәгълүмәтне электр энергиясен (егәрлеген) куллануның социаль нормасын куллану максатларында тапшыру тәртибен һәм срокларын билгели.

2. Регламентта кулланылучы төшенчәләр Положениедәге мәгънәдә үк кулланыла.

## II. Электр энергиясен (егәрлеген) куллануның социаль нормасын билгеләү

3. Электр энергиясен (егәрлеген) куллануның социаль нормасын билгеләү максатларында:

3.1. Электр энергиясен гарантияле бирүче һәм коммуналь хезмәтләрне башкаручылар социаль норманы куллану датасына кадәр 4 айдан да соңармыйча Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетына (арытаба – Дәүләт комитеты) Татарстан Республикасы территориясендәге торак биналарда электр энергиясен куллануның еллык күләме турында, Положениенең 1нче кушымтасына ярашлы формада, мәгълүмәт тапшыралар.

3.2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары социаль норманы куллану датасыннан өч айдан да соңармыйча Дәүләт комитетына Татарстан Республикасы территориясендәге торак биналар-

да яшәүче теркәлгән затларның саны турында, Положениенең 3нче кушымтасына ярашлы формада, мәгълүмәт тапшыралар.

3.3. Дәүләт комитеты:

– электр энергиясен (егәрлеген) куллануның социаль нормасын шәһәр җирләрендәге, билгеләнгән тәртиптә стационар ашамлык әзерләү электр плитәләре белән җиһазланмаган торак биналарда теркәлгән, 10000 кешедән ким булмаган кулланучыларның еллык куллану күләме турындагы, шулай ук әлеге биналарда Положение билгеләгән срокларда һәм тәртиптә теркәлгәннәрнең саны турындагы сайланма белешмәләр нигезендә билгели;

– халыкка һәм кулланучыларның аңа тиңләнгән категорияләренә социаль норма чикләрендә һәм аннан күбрәк, Положение билгеләгән срокларда һәм тәртиптә бирелә торган электр энергиясенә (егәрлегенә) бәяләрне (тарифларны) урнаштыра;

– электр энергиясен (егәрлеген) куллануның социаль нормасын урнаштыру турында карар кабул ителгән көннән соң 10 көн эчендә үзенең рәсми сайтында һәм рәсми мәгълүмәт басмасында электр энергиясен (егәрлеген) куллануның социаль нормасын куллануның шартлары турында мәгълүмәт игълан итә.

## III. Электр энергиясен (егәрлеген) куллануның социаль нормасын куллану

### Электр энергиясен (егәрлеген) куллануның социаль нормасын куллану мәсьәләләре буенча мәгълүмәт алмашуда катнашучылар

4. Электр энергиясен (егәрлеген) куллануның социаль нормасын куллану мәсьәләләре буенча мәгълүмәт алмашуда катнашалар:

– Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (арытаба – ТР ТАһәмТКХМ);

– Татарстан Республикасы Мәгълүмәтләштерү һәм элемтә министрлыгы;

– Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы;

– Россия Федераль миграция службасының Татарстан Республикасы буенча идарәсе;

– Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе;

– Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары;

– халыкны социаль яклау органнары;

– коммуналь хезмәт күрсәтүчеләр;

– электр энергиясен гарантияле бирүче.

### Мәгълүмәт алмашу объекты

5. Мәгълүмәт алмашу объекты булып Татарстан Республикасы территориясендә электр энергиясен (егәрлеген) куллануның социаль нормасын куллану өчен кирәкле түбәндәге мәгълүмәт тора:

– Россия Федерациясе гражданнарын яшәү урыны буенча теркәү исәбенә

алу һәм аннан төшерү фактлары турында (Россия Федерациясе чикләрендә яшәү урынында теркәлмәгән затларга карата – яшәп тору урынында теркәү исәбенә алу һәм аннан төшерү фактлары турында) мәгълүмәт;

– Татарстан Республикасы территориясендәге торак биналарда яшәүче теркәлгән затларның саны турында мәгълүмәт (Положениенең 3нче кушымтасы);

– йортларны газ плитәләре һәм электр плитәләре, электр белән җылыту, электр белән су җылыту приборлары белән җиһазлау турында мәгълүмәт;

– торак бинаның аварияле торак фондына я 70%ка һәм күбрәк тузган торак фондына кертелүе турында мәгълүмәт;

– уртак хуҗалык итү турында мәгълүмәт (махсуслашкан торак фонды биналарында яшәүчеләр өчен);

– махсуслашкан торак фонды биналарында яшәүче, уртак хуҗалык итү белән берләшмәгән гражданнарның йорт хуҗалыклары турында мәгълүмәт (бер яшәүчегә карата);

– торак биналарның махсуслашкан торак фондына каравы турында мәгълүмәт;

– Татарстан Республикасы территориясендәге торак биналарда ялгыз яшәүче, картлык я инвалидлык буенча пенсия алучы затлар турында мәгълүмәт;

– Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларына ярашлы рәвештә күп балалы гаиләләр категориясенә кертелгән гаиләләр яшәүче йорт хуҗалыклары турында мәгълүмәт;

– үзендә инвалидлар, инвалид балалар булган гаиләләр яшәүче йорт хуҗалыклары турында мәгълүмәт;

– үзендә караучысыз калган балалар булган гаиләләр яшәгән йорт хуҗалыклары турында мәгълүмәт;

– хисап дәверендә торак биналарда электр энергиясен (егәрлеген) аны куллануның социаль нормасы чикләрендә һәм аннан күбрәк куллану турында мәгълүмәт (Положениенең 7нче кушымтасы);

– электр энергиясен аны куллануның социаль нормасы чикләрендә һәм аннан күбрәк куллану турында мәгълүмәт (Положениенең 8нче кушымтасы).

## Мәгълүмәт алмашуның максаты

6. Татарстан Республикасы территориясендә мәгълүмәт алмашуда катнашучылар арасында мәгълүмәт бәйләнеше шундый максатларда башкарыла:

– электр энергиясен (егәрлеген) куллануның социаль нормасын куллану;

– халык һәм кулланучыларның аңа тиңләнгән төркемнәре электр (егәрлеген) аны куллануның социаль нормасы чикләрендә һәм аннан күбрәк кулланган өчен исәпләшү өлкәсендә Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары таләпләрен үтәүгә контроль.

## Мәгълүмәт алмашуда катнашучыларның хокуклары һәм бурычлары

7. Хокуклар һәм бурычлар Регламент кысаларында мәгълүмәт алмашуда катнашучыларның барсына да кагыла.

8. Мәгълүмәт алмашуда катнашучылар хаклы:

– мәгълүмәт алмашуда бүтән катнашучыдан кирәкле мәгълүмәтне сорап алырга, әгәр аны бирү гамәлдәге законнар һәм Регламент белән күздә тотылса.

9. Мәгълүмәт алмашуда катнашучылар бурычлы:

– Татарстан Республикасында электр энергиясен (егәрлеген) куллануның социаль нормасын куллану өчен кирәкле мәгълүмәтне гамәлдәге законнар һәм Регламент билгеләгән тәртиптә һәм срокларда бирергә;

– үз компетенцияләре кысаларында кулланучыларга (сорату буенча) электр энергиясен куллануның социаль нормасын куллану мәсьәләләре буенча мәгълүмәт бирергә.

Мәгълүмәт алмашуда катнашучыларга мәгълүмәт тапшыруның сроклары һәм тәртибе

10. ТР ТАһәмТКХМ

– 2016 елның 1 январена кадәр торак фонды объектларына капиталь ремонт һәм аларның торышына мониторинг буенча дәүләт программасын формалаштыру һәм аның үтәлешенә мониторинг буенча мәгълүмәт-анализ системасында урнаштыру өчен мәгълүмәт алмашуда катнашучылардан алынган белешмәләр исемлеген формалаштыра;

– һәр айның 1нче числосына кадәр Татарстан Республикасы Мәгълүмәтләштерү һәм элемтә министрлыгы адресына социаль норманы исәпләү өчен актуальләштерелгән мәгълүмәтне тапшыруны тәэмин итә;

– үзенең рәсми сайтында социаль норманы куллану турындагы, йорт хуҗалыклары составын коммуналь хезмәтләрне башкаручыларга хәбәр итү юлы белән төгәлләү тәртибе турындагы мәгълүмәтне игълан итә.

11. Татарстан Республикасы Мәгълүмәтләштерү һәм элемтә министрлыгы:

– 2016 елның 1 январена кадәр торак фонды объектларына капиталь ремонт һәм аларның торышына мониторинг буенча дәүләт программасын формалаштыру һәм аның үтәлешенә мониторинг буенча мәгълүмәт-анализ системасында урнаштыру өчен мәгълүмәт алмашуда катнашучыларга бирелә торган мәгълүмәтнең форматын һәм составын билгели;

– 2016 елның 1 апреленә кадәр ТР ТАһәмТКХМнан алынган мәгълүмәттән чыгып бердәм белешмәләр базасын формалаштыра;

– электр энергиясе бирү буенча социаль норманы исәпләү өчен кирәкле мәгълүмәтнең бердәм белешмәләр базасының эш итүен һәм ай саен актуальләштерелүен тәэмин итә.

12. Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлекчәсе агымдагы айның 25нче числосына кадәр, Россия Федерациясенең персональ белешмәләрне саклау турындагы законнарын үтәгән хәлдә, Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль ярдәм министрлыгына картлык һәм инвалидлык буенча пенсия алучылар турында белешмәләр тапшыра.

13. Халыкны социаль яклау органнары һәр айның 10нчы числосына кадәр Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгына шундый мәгълүмәтне тапшыралар:

– Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларына ярашлы рәвештә күп балалы гаиләләр дип танылган гаиләләр яшәгән йорт хуҗалыклары турында;

– үзендә инвалидлар, инвалид балалар булган гаиләләр яшәгән йорт хуҗалыклары турында;

– үзендә караучысыз калган балалар булган гаиләләр яшәгән йорт хуҗалыклары турында.

14. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы халыкны социаль яклау органнарыннан һәм Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы буенча бүлегеннән алынган мәгълүматны ай саен мәгълүматны алган айдан соң килүче айның 1 нче көненә кадәр ТР Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгына тапшыра.

15. Россия Федераль миграция службасының Татарстан Республикасы буенча идарәсе һәр айның 10нчы числосына кадәр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарына шундый мәгълүмәтне тапшыра:

– Россия Федерациясе гражданнарын яшәү урыны буенча теркәү исәбенә алу һәм аннан төшерү фактлары турында;

– Россия Федерациясе чикләрендәге яшәү урынында теркәлмәгән затларны тору урыннары буенча теркәү исәбенә алу һәм аннан төшерү фактлары турында.

16. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәр айның 20нче числосына кадәр ТР ТАһәмТКХМга шундый мәгълүмәтне тапшыралар:

– Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән гражданнар саны турында;

– махсуслашкан торак фондының торак биналарында яшәүче гражданнар турында;

– уртак хуҗалык итүләр турында (махсуслашкан торак фондының торак биналарында яшәүче гражданнар өчен);

– махсуслашкан торак фонды биналарында яшәүче, уртак хуҗалык белән берләшмәгән гражданнарның йорт хуҗалыклары турында (бер яшәүчегә карата)

17. Электр энергиясен гарантияле бирүче:

– халыкка социаль норма чикләрендә һәм аннан күбрәк бирелә торган электр энергиясе күләмен аерым исәпләүне башкара;

– квартал саен үз эшчәнлеге территориясендәге барлык йорт хуҗалыклары буенча, Положениенең 8нче кушымтасына ярашлы рәвештә, узган кварталда халыкка социаль норма чикләрендә һәм аннан күбрәк бирелгән электр энергиясе күләмнәре турында җыелма хисапны формалаштыра һәм аны шул кварталдан соң килүче айның азакгы числосыннан да соңармыйча ТР ТАһәмТКХМга һәм Дәүләт комитетына тапшыра;

– кулланучыларны ярашлы йорт хуҗалыгы төркеменә кертү өчен кирәкле белешмәләрне алар белән бергә дөресләүне үткәрә;

– түләү документында кулланучыга торак бинаның тибы һәм кулланучының йорт хуҗалыгы төркеме турында, социаль норма чикләрендәге һәм аннан күбрәк электр энергиясенә бәяләр (тарифлар) турында, хисап чорында электр энергиясен социаль норма чикләрендә һәм аннан күбрәк куллану күләмнәре турында, коммуналь хезмәтләр өчен түләүнең электр бирү буенча күләме (шул исәптән тулай йорт хаҗәтләренә бирелгәне) турында, кулланылган электр энергиясе өчен түләүләр билгеләгәндә социаль норманы куллану өчен кирәкле белешмәләрнең үзгәрүе турыда коммуналь хезмәтләр бирүчегә 3 айга 1 тапкыр хәбәр итәргә тиешлек турында мәгълүмат бирә.

18. Коммуналь хезмәтләрне башкаручылар:

– электр энергиясе (егәрлеге) бирүчегә коммуналь хезмәтләр күрсәтүче электр энергиясе бирүнең социаль нормасы чикләрендә һәм аннан күбрәк биргән электр энергиясе күләмнәре турында, Положениенең 7нче кушымтасына ярашлы формада һәм Кагыйдәләрдә каралган, идарә итүче оешма яки торак ияләре ширкәте яисә торак кооперативы яисә башка махсуслашкан куллану кооперативы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 14.02.2012 ел № 124 карары белән расланган  ресурс бирүче оешмалар белән килешүләр төзегәндә мәҗбүри булган  срокларда, әгәр электр энергиясе бирү килешүендә бүтән срок билгеләнмәгән булса, ай саен, хисап аеннан соң килүче айның бишенче числосыннан да соңармыйча, белешмә бирәләр.

– кулланучыларны ярашлы йорт хуҗалыгы төркеменә кертү өчен кирәкле белешмәләрне алар белән бергә дөресләүне үткәрәләр;

– түләү документында кулланучыга торак бинаның тибы һәм кулланучының йорт хуҗалыгы төркеме турында, социаль норма чикләрендәге һәм аннан күбрәк электр энергиясенә бәяләр (тарифлар) турында, хисап чорында электр энергиясен социаль норма чикләрендә һәм аннан күбрәк куллану күләмнәре турында, коммуналь хезмәтләр өчен түләүнең электр бирү буенча күләме (шул исәптән тулай йорт хаҗәтләренә бирелгәне) турында, кулланылган электр энергиясе өчен түләүләр билгеләгәндә социаль норманы куллану өчен кирәкле белешмәләрнең үзгәрүе турыда коммуналь хезмәтләр бирүчегә 3 айга 1 тапкыр хәбәр итәргә тиешлек турында мәгълүмат бирәләр;

– электр энергиясе (егәрлеге) бирүченең соратуы буенча бер атна эчендә электр энергиясен (егәрлеген) хезмәт күрсәтелүче торак биналарда еллык куллану күләме турында (электр энергиясен (егәрлеген) ялгыз яшәүче пенсионерларның һәм пенсионер гаиләләренең куллануы күләмнәрен аерым күрсәтеп), Положениенең 8нче кушымтасына ярашлы формада, мәгълүмат бирәләр.

Мәгълүмәт алмашуда катнашучыларның җаваплылыгы

19. Мәгълүмәт алмашуда катнашучылар түбәндәгеләр өчен җаваплы:

– персональ белешмәләрне саклау Россия Федерациясе законнарын үтәмәгән өчен;

– бирелә торган белешмәләрнең дөреслеген, үз вакытында бирелүен һәм

актуальлеген тәэмин итмәгән өчен;

– гамәлдәге Россия Федерациясе законнарына ярашлы рәвештә шушы Регламент билгеләгән бурычларын үтәмәгән я җиренә җиткереп үтәмәгән өчен;

– мәгълүмәт алмашуда катнашучы башкалар өчен кирәкле мәгълүмәтне бозуга яки яшерүгә юнәлтелгән гамәлләре өчен;

– мәгълүмәт алмашу процессында алынган белешмәләрнең конфиденциальлек һәм куркынычсызлык режимын үтәмәгән өчен.